**Интеллектуаль уен,**
**4 класс**

# Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел



**Сибгатуллина И.И. учитель начальных классов**

**МОУ «СОШ ст.Миннибаево» Альметьевский район,**

**республика Татарстан**

# “Синонимнар”

# “Антонимнар”

**Тел дигән дәрья бар,**
**Дәрья төбендә мәрҗән бар.**
**Белгәннәр чумып алыр,**
**Белмәгән карап калыр.**

Нәкый ага Исәнбәт

- Хуплау яки котлау билгесе итеп кул чабу

алкыш

- Вакыт- вакыт фонтан формасында су һәм пар атып чыгара торган кайнар чишмә

гейзер

- Ун көнлек вакыт

декада

- Профессиональ аучы

егерь

# Икенче бирем.
# Бирелгән сүзләрнең хәрефләреннән яңа сүзләр ясап язарга.

“Синонимнар”

- азат-таза
- таш-
- агач-
- кич-
- ирек-
- чак-
- кач-

“Антонимнар”

- атна-тана
- арка-
- төс-
- кое-
- кия-
- бара-
- идән-

# Өченче бирем.
# Мәкаль төгәл булсын.

- Өең кысан булса да

күңелең иркен булсын

- Олы өйгә ни кирәк,

кече өйгә шул кирәк

- Җәен актан киен,

кышын карадан киен

- Яхшы тел-яз кебек,

яман тел-көз кебек

- Туры  әйткән котылган,

ялганлаган тотылган

- Сөйдергән дә-тел,

биздергән  дә-тел

- Күп сүзнең

азы яхшы

- Ялгыз ял күрмәс,

күмәк ару белмәс

# Дүртенче бирем.
# Кем тизрәк таба.

- Сизгер булмау, сак булмау.

Авыз ачып йөрү

- Үпкәләү, ачулану, хәтере калу.

Авыз турсайту

-Йортка яки эшкә уңышсызлык китергән кешегә әйтелә.

Авыр аяклы

- Кайгы, борчу яки аңлашылмаучылык, канәгать-сезлек аркасында туган сүзсезлек.

Авыр тынлык

- Вакытлы юләрлек бетеп, тыйнаклану, акыллылану.

Акылга утыру

- Әхлак нормаларына сыймаган гадәтләр, ярамаган, тыелга эшләр.

Бозык юл

- Күңелгә ятышсыз сүз сөйләүчегә яки теләк теләүчегә карата әйтелә.

Авызыннан җил алсын

- Берәр сәбәп аркасында авырый башлау, сәламәтлеген җую.

Авыруга сабышу

# Табышмаклар

Көн һәм төн нәрсә белән бетә?

“Н” хәрефе белән

Иң кыска ай кайсысы?

Май

Дәрес ахыры нәрсә белән бетә?

“С” хәрефе белән

Нинди сүздә алты “н” бар?

Алтын

Утыз “я” хәрефеннән торган кеше исеме ничек була?

Зоя

Беренче иҗеге-җирнең иярчене; икенче иҗеге-җәзалау урыны; кушып укыганда-кеше исеме.

Айдар

Бер иҗегем-төс минем,
Икенчесе-сыеклык.
Өченчесе болай ди:
-Безнең авыл бик бай,-ди.

Аксубай

Азиядәге бер тауның исемен алам: беренче иҗеге-әйбернең төсен белдерә, икенче иҗеге-йорт хайванының исеме.

Алтай

Түтәлдә нинди ике нота үсә?

Фасоль

Бер иҗегем башта,
Икенчесе-кышта,
Кушып укысаң икесен,
Эт кушаматын әйтерсең.

Кашкар

# Сүзләр

**Фанис Яруллин**

Башым тубал. Ә тубалда сүзләр.
Сүзләрнең бар төрле-төрлесе.
Командирдай алдан йөрүчесе.
Кеше күңеле кебек серлесе.
Йөри- йөри тузып беткәне бар,
Бар шулай ук яңа туганы.
Мөстәкыйле, ярдәм итүчесе,
Койрык белән мөгез сыманы.
Бар шундые-ялгыз гына чакта
Санга каралмаучы сансызы,
Яки
Телсез кыңгыраудай җансызы;
Тиңгә тиңен, ишкә ишен эзләп,
Сүзләр тезәм кәгазь өстенә.
Теләсә ничек, ләкин эш италмыйм,
Хөкемдарлык минем кечкенә,
Һәрберсенә үзенеке кирәк,
Үзенең пары, үзенең сыңары;
Халык белән хаклык сүзе кебек
Аерылмыйча яши торганы,
Ике кулдай бер пар булганы.